Чыгу көне: 30.12.2022

# Хуш киләсең, Яңа ел!



## Аз-маз тарих

Яңа елны борынгыдан ук бәйрәм иткәннәр. Тик ул төрле илдә төрле вакытка туры килгән. Һиндстанда, төрки дәүләтләрдә аны 21

нче мартта – көн белән төн тигезләшкәч, кыр эшләре башлангач билгеләп үткәннәр, мул уңыш алуны теләгәннәр. «Нәүрүз мөбарак булсын!» дигәнне ишеткәнегез бардыр.

Борынгы Грециядә Яңа елны сатир костюмнары киеп, бик күңелле итеп 22нче июньдә – елның иң озын көне җиткәч бәйрәм ит-кәннәр.

Ә Борынгы Мисырда Яңа елны Сириус йолдызы хөрмәтенә сентябрьдә каршы алганнар. Римда б.э.га кадәр 46 елда им-ператор Юлий Це-зарь хөрмәтенә кер-телгән 365 көнлек календарь буенча 1нче гыйнварда бәйрәм итә баш-лаганнар.

Борынгы Русьта, христиан дине кабул ителгәч, Яңа елны 1нче мартта билгеләп үтә башлыйлар. Аңа кадәр кояшка табынучы халыклардагыча, 21нче март бәйрәм саналган. Петр 1 указы белән, ел башын 1нче гыйнвардан исәпләргә дип кертелә. Бәйрәмгә чыршылар бизәү, маска, гирлянда, фейерверклар куллану да шул заманнан калган.

## Яңа ел алдыннан сораулар

Яңа ел алдыннан мәктәп укучыларына 5 сораугa җавап бирергә куштык

**31 нче декабрь минем өчен…**

Нәҗметдинова Диана
Спа салонга сертификат
Щеколдина Ирина
Нью-Йоркка билет
Кәримова Камилә
Гирляндалар

**Кышкы каникулда мин ...**

Нәҗметдинова Диана
Озак йоклар идем...
Щеколдина Ирина
Кар көртендә аунар идем.
Кәримова Камилә
Шугалакта йөрер идем...

**Барыгызга да минем теләкләрем:**

Нәҗметдинова Диана
Саулык, бәхет, мәхәббәт
Щеколдина Ирина
Яхшы киләчәк
Кәримова Камилә
Теләкләрегез чынга ашсын!

Без дә сезнең теләкләрегезнең чынга ашуын теләп калабыз.

Редакциядән

## 2023 ел– Кара Куян елыннан нәрсә көтәргә?

Аның стихиясе-су. Куян елында түбәндәге танылган кешеләр туган: А. Энштейн, Э. Рязанов, У. Хьюстон, Р. Сәхәбиев, Г. Тимерҗанова, З. Сәфиуллин һ.б.

Бу ел гаилә бәхете, игелек һәм тыныч, матур мөнәсәбәтләр алып килер, дип ышандыралар.


**Декабрь аенда «Башлык һәм аяк киеме”** көне узды. Укучылар бу көнне матур баш киемнәре, аяк киемнәре киеп, тышкы кыяфәтләрен күрсәттеләр. Кызык образлар да бар иде араларында.

## Чебоксарга бару хатирәләре

Мин Чебоксарга барудан алган тәэссирләрне беркайчан да онытмамын шикелле...
Безне “61 нче урта гомум белем бирү мәктәбе”нең җитәкчеләре һәм укучылары бик җылы каршы алды. Шәһәр тарихы, мәдәнияты, халкы, гореф-гадәтләре белән саен үткәрелә торган

**«Хорлар көрәше»** фестивале безнең мәктәпнең традицион чарасына әйләнде. Фестиваль Татарстанда туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елының һәм РФ фән һәм технология елының йомгаклау вакыйгасы булды.

10 нчы декабрь көнне 1-4 нче сыйныфлар өчен **«Сәламәтлек көне»** узды. Бөтен башлангыч сыйныф укучылары спорт киеменнән килгән иде. Көн иртәнге зарядкадан башланды. Аннары күңелле старт һәм тематик сыйныф сәгатьләре, викторина, түгәрәк өстәл, интерактив уеннар уздырылды. Сәламәтлек көне һәр укучыга файдалы узды



# «Хәйрия »



1993 елдан 3 декабрь **Халыкара инвалидлар көне** итеп билгеләнде. Инвалидлар ункөнлеге дәвамында мәктәбебездә дә шактый игелекле эшләр башкарылды. Ул эшләрнең укучылар өчен тәрбияви әһәмияте дә бик зур. Игелекле эшләрдә катнашырга теләк белдерүчеләрнең артуы да куандыра. Әти-әниләрнең, әбиләрнең дә мәктәпләр оештырган чараларга катнашуы балалар өчен бернинди сүзләр белән дә алыштырып булмый торган тәрбияви үрнәк.

Әлеге дата белән бәйле рәвештә мәктәбебездә декабрь башын инвалидлар декадасы итеп үткәрү традициягә керде, төрле чаралар, ярминкәләр уздырылды.

Хәйрия ярминкәсендә укытучылар, әти-әниләр, укучылар бик теләп катнаштылар. Ярминкәдә җыелган бүләкләр, тәм-томнар мөмкинлеге чикләнгән кешеләргә, мәктәбебездә укучы инвалид балаларга да хәйрия күчтәнәчләре тапшырылды. "Шәфкатьлелек ярминкәсе"нә өлеш керткән һәркайсыгызга рәхмәт!

Инвалидлар декадасына багышланган акцияне тәмамлап, без, игелеккә юлыбызны туктатмыйбыз, чөнки бары тик йөрәкләр генә ачыла.



«Халәт»

Берни ишетәсем килми,
Килми берни күрәсем.
Яшәү дәртем булмаса да,
Килми кебек үләсем.
Күңелемдә гел болытлар,
Соры да кара гына.
Ичмасам кояш та чыкмый
Болытлар арасына.
Әллә нинди халәт бит бу,
Әй, Ходаем, бир түзем.
Күпме халык арасында
Яшим кебек берүзем.
Алда яңа өметләр юк,
Юк буй җитмәс хыял да.
Бөркеткә дә нәкъ шулайдыр
Бәрелгәндә кыяга.
Бәхетсез мизгелләр кирәк
Бәхетне аңлар өчен.
Бер чирләп карау да җитә
Саулыкны саклар өчен.

Ләйлә Дәүләтова

# Эшлекле әңгәмә

## Бездә кунакта ФСБ хезмәткәре

ФСБ– Россия Федерациясе иминлеген тәэмин итү бурычларын үз вәкаләтләре чикләрендә хәл итүне гамәлгә ашыручы Федераль куркынычсызлык хезмәте органнарының бердәм үзәкләштерелгән системасы.

Россия Федераль куркынычсызлык хезмәте эшчәнлеге белән җитәкчелек итү Россия Федерациясе Президенты тарафыннан гамәлгә ашырыла.1995 елның июнендә Россия Федерациясе контрразведка федераль хезмәтен үзгәртеп кору (үзгәртеп кору) юлы белән оештырыла.

13 нче декабрьдә безнең «Уңыш белән әңгәмә» мәктәп проектында ФСБ хезмәткәре  булды. Ул безгә үзенең эшенең үзенчәлеге, авыр һәм кызыклы яклары белән таныштырды. Укучыларыбыз кызыксындырган  сорауларына да җаваплар ишеттеләр.

ФСБ хезмәткәрләре нинди эшләр белән шөгыльләнә?- дигән сорауга ул түбәндәгечә җавап бирде:

*Федераль куркынычсызлык хезмәте органнары (ФСБ) Россия Федерациясе законнары нигезендә шпионажны ачыклау, кисәтү һәм ачу буенча оператив-эзләү чараларын тормышка ашыралар.*

*Мәгълүмати куркынычсызлыкны тәэмин итү-федераль КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК хезмәте органнарының үз вәкаләтләре чикләрендә алар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшчәнлеге.*

Кунагыбыз ахырда түбәндәге киңәшен әйтте: «Әгәр сез һөнәр сайлауда кыенсын сагыз, барысын да сынап карарга кирәк, һәм сез, һичшиксез, үзегезнең күңелегезгә килгәнен табарсыз».

Килгән кунагыбызга олы рәхмәтебезне җиткерәбез!

Редакциянең адресы:
420101, Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576
Тираж – 50 экз.

Баш мөхәррир
һәм дизайнер:
Габдуллаҗанова А.Ф.

Редколлегия әгъзалары:
Сафина Камилла, Соколова София, Овезова Ләйлә, Акмаева Элиза